ТУЛИСЕ ЮК

Ике һәм аннан да күбрәк бала тәрбияләүче гаиләләр өчен яңалык бар

> 2

МИЛЛИ БИЗӘКЛӘР

Әгерҗе районында мариларның Семык бәйрәме гөрләде

> 4

КОЛОРАДО ТҮГЕЛ

Бу кортны күреп, авыл халкы, бәрәңгесез калмагаек, дип борчыла

> 4

ТАТАРЧА СУГА

«Ак барс» һөҗүмче Дамир Җәгъфәров белән килешү төзеде

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 79 (29046) | Сишәмбе | 6 июнь | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Зөһрә САДЫЙКОВА

ЯШЕЛ «ДОШМАН»ГА КАРШЫ

Яшәеш

Депутатлар Дәүләт Думасына балтырганга кагылышлы ике закон проектын кертергә ниятли. Аларның берсе Җир кодексында «инвазив үсемлек» (таралуы биологик күптөрлелеккә йогынты ясарга мөмкин булган) дигән төшенчәне беркетүдән гыйбарәт булса, икенчесе федераль дәрәҗәдәге җирләрдә балтырган үрчеткән өчен штраф салуны күздә тота.

«ВТ» архивыннан

Балтырганның ни дәрәҗәдә агулы үсемлек икәнлеген язып, аңлатып торырга кирәкмидер дә, шулай да тагын бер кат искә төшерү зыянлы булмас. Россельхознадзорның фитосанитар һәм орлык сыйфаты күзәтчелеге, орлык тикшерү бүлеге җитәкчесе Альберт Кадыйров сөйләвенчә, июльдән августка кадәр чәчәк атып, җимешләре июльдән сентябрьгә кадәр өлгерә торган балтырганның агулы матдәләре кеше яки терлек тиресенә эләккән очракта тәнне пешерә. Саклану чарасын күрмәгән очракта, пешү бик каты булырга, 3–6 айга кадәр сузылырга мөмкин. Шуңа күрә балтырганның нәрсә икәнен белүчеләр, тәнгә согы тигән очракта, тизрәк юып төшерә, әлеге зарарланган урын кояш нурлары белән тагын да азып китмәсен өчен сакланырга тырыша. Балтырганның согы күзгә керсә, аеруча куркыныч, ул кешене сукыр калдырырга да мөмкин. Аның зыяны кешеләргә генә түгел, табигатькә дә зур. Балтырган үскән җирнең көче бетә, ди белгечләр.

Шунысы бик начар: балтырган бик тиз таралып, ул биләгән җирләр елдан-ел арта. Моның шулай икәнлеген аңлар өчен, саннарга күз салу да җитә. «Россельхозцентр»ның Татарстан буенча филиалы җитәкчесе урынбасары Гүзәл Хөсәнова җиткергән мәгълүматлар буенча, Татарстанда балтырган үрчи торган мәйданнар елдан-ел арта. Әйтик, 2021 елда республиканың 30 районында әлеге агулы үсемлек биләгән мәйданнар 1,2 мең гектар булган. Узган ел исә мондый участоклар 1,38 мең гектарга җиткән. Чагыштыру өчен: 2012 елда мондый җирләр – 109, 2018 елда 600 гектар булган. Хәзерге вакытта балтырганнан аеруча Биектау, Балтач, Арча, Әгерҗе, Питрәч районнарында һәм Казанда яшәүчеләр иза чигә. Әлеге агулы үләнне чокыр-чакырларда, сулыкларда, халыкның бакчаларында, юл читләрендә күпләп очратырга мөмкин.

Балтырган Биектау районының Суыксу җирлегенә кергән авылларында да күп. Аеруча халкы аз булган Чәмәк авылында азган.

– 1980 нче елларда балтырганны безнең тирәдә 4 гектар җиргә махсус чәчкән булганнар. Элек колхозда да, хуҗалыкта да маллар күп иде, үләнгә азарга ирек булмады. Соңгы елларда, кызганыч, ул нык үрчеде. Аеруча сулы урыннарда күп, – диде җирлек башлыгы Рамил Низамиев.

Аның сүзләренчә, үз хуҗалыгында булган үләнне халык үзе чаба. Ә менә чокыр-чакырлы, сулы урыннарны чабып бетерү мөмкин түгел. Билгеле булганча, берничә ел элек Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы агулы үсемлеккә каршы химик ысуллар белән көрәшү өчен акча бүлеп бирә башлаган иде. Аның нәтиҗәсе булдымы соң?

– Ике ел рәттән эшкәрткән җирләрдә балтырган юкка чыгып бара. Менә быел да эшкәртергә әзерләнәбез. Химик эшкәртүдән соң балтырган кайдадыр берән-сәрән генә калды, кайдадыр бөтенләй бетте. Химик ысул белән эшкәрткәннән соң, чабасы да юк. Иң мөһиме – эшләрне чәчәк атканчы башкарып чыгу. 4 метрга кадәр үсә бит ул. Бик усал үсемлек. Яныннан узып китсәм дә, миндә аллергия башлана, – диде Рамил Низамиев.

«Россельхозцентр»ның Татарстан буенча филиалы белгечләре аңлатуынча, балтырган ике тапкыр эшкәртелергә тиеш. Май ахыры – июнь башында химик һәм механик эшкәртү узса, җәй урталарында гербицидлар ярдәмендә яки кулдан эшкәртелә. Әлдермеш авылында яшәүче Тәлгат Сабиров та балтырганга каршы көрәшне иртә яздан ук башларга кирәк, дип саный.

– Балтырган да, башка үсемлекләр кебек үк, май аенда чыга башлый. Иң нәтиҗәлесе – аны чыгу белән эшкәртү. Хәзер алар биегәйгәннән-биегәя бара. Дымлы көнне хәтта 10 сантиметрга кадәр үсәргә дә мөмкин. Бер елны Әлдермеш һәм Өбрә авылларында, эксперимент буларак, балтырган үсә торган җирләрнең бер өлешен көздән сукалаган идек. Ләкин яз көне яңадан чыкты. Орлыгы җитешкәнче чабарга тырышсак та, барыбер тишелеп чыга. Шуңа күрә бу эшләрне бертуктаусыз эшләргә, бер балтырганга каршы да берничә ел көрәшергә кирәк. Соңгы елларда аларга каршы нәтиҗәле көрәш башланды, – диде ул.

Фәнни-тикшеренү институтының әйдәп баручы белгече Екатерина Баранова фикеренчә, балтырган үрчеткән өчен штраф салганчы, киресенчә, аңа каршы көрәшкәннәрне бүләкләсәләр, файдасы яхшырак булыр иде.

– Хөкүмәт органнары урынында булсам, штраф салганчы, бүләкләр идем, – ди ул. – Моның өчен ришвәт тә, башка нәрсәләр дә кирәк булмаган бәйсез кешеләрдән торган комиссия төзергә кирәк. Алар урыннарга чыгып тикшерсеннәр иде. Әгәр уңай үзгәрешләр бар икән, бакчачылык ширкәтләренә, мәсәлән, ниндидер бонуслар бирелсен. Әйтик, чүпләрен бушлай чыгарсыннар. Яки электр энергиясе өчен ташлама ясасыннар. Менә шулай иткәндә ниндидер уңай нәтиҗәгә ирешергә мөмкин.

Биолог фикеренчә, әлеге әрсез үсемлек үскән урынга кара төстәге тукыма каплап кую да булышыр иде. Ике елдан соң бу урынга үлән чәчәргә кирәк. Ләкин бу да балтырганны тулысынча бетерер, дигән ышаныч юк, ди белгеч.

БАЛТЫРГАННАН НИЧЕК КОТЫЛЫРГА?

➤ Балтырган сабакларын чәчәк атып бетергәндә һәм орлык формалашкан вакытта чабу тыела. Бу, беренчедән, бернинди дә нәтиҗә бирми, икенчедән, бүленеп чыккан согыннан пешәргә дә мөмкин. Чабылган үләнне сак кына бер урынга җыеп, яндырган очракта гына, аның таралуын киметергә мөмкин.

➤ Чабылган үләнне киптерергә калдырырга ярамый, чөнки хәтта мондый үсемлекнең дә орлыгы өлгерергә мөмкин.

➤ Үләнне орлыклары тулысынча җитлеккән вакытта да чабарга ярамый. Болай эшләгәндә, алар җиргә коелып, бөтен территория буенча тизрәк таралачак. Ә җилле көнне чапсагыз, әрсез үлән күрше мәйданнарга да «кунак»ка керергә мөмкин.

Эшле итәләр

23 июньдә Татарстанның өч шәһәрендә эш эзләүчеләр өчен «Работа России. Время возможностей» Бөтенроссия ярминкәсе үткәреләчәк. Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы матбугат хезмәте хәбәренә караганда, чара Казанда – «Горки-Әмәт» урманында, Чаллыда – «КамАЗ» мәдәният сараенда, Түбән Камада «Ковер» яшьләр башлангычлары үзәгендә узарга тиеш. Әйтик, Чаллыда 25 зур предприятие 1,5 меңнән артыграк вакансия (хезмәт хакы – 40 меңнән 120 мең сумга кадәр) тәкъдим итәчәк. Алар арасында «КАМАЗ», «Ремдизель», «ТЭМПО», башка шундый заводлар бар. Ярминкәдә үзеңә кулай эш табу, мастер-класслар һәм тренинглар узу мөмкинлеге тудырыла.

Ярминкәгә килүчеләр белгечләр ярдәмендә үзләренең карьерасын планлаштыра алачак. Шулай ук үз эшеңне ачу, резюме тутыру һәм әңгәмәләшү серләренә өйрәтәчәкләр.

Дару булачак

Россия Хөкүмәте, кирәкле дару запасын булдыру өчен, илгә препаратлар кертү һәм теркәүнең гадиләштерелгән тәртибен киләсе ел ахырына кадәр озайткан. Россия Премьер-министры Михаил Мишустин искә төшереп үткәнчә, илебезгә каршы кертелгән чикләүләр аркасында күп кенә логистика чылбырлары өзелгән. Дару җитештерүчеләр үзләренең товарын эчке базарга тизрәк чыгара алсын өчен гадиләштерелгән процедуралар кулланылачак.

Хөкүмәт башлыгы сүзләренә караганда, биредә сүз иң элек Россиядә сатылучы даруларның аналогларын теркәү һәм дарулар кертүгә рөхсәтләр алу турында бара.

Беренче смена башланды

Татарстаннан 600ләп бала Анапа һәм Кырым лагерьларына киткән. Быел Кара диңгез яры буенча республикадан барлыгы 5 меңләп бала ял итәчәк. «Черноморец» республика ял үзәге дүрт сменада – 4412, «Сәләт-Ак Барс» Яшьләр үзәге 880 баланың ялын оештырачак.

Яшьләр эшләре министры Ринат Садыйков билгеләп үткәнчә, юлда да, шулай ук ял вакытында да балаларның иминлеге аерым игътибар үзәгендә тотылачак. Балалар һәм вожатыйларны ял урынына китерү һәм кире алып кайту өчен махсус поездлар бирелә.

Лагерьларга китүче балаларның бер өлеше – «Дустанә сыйныф серләре» республика бәйгесендә җиңүчеләр.

Сүз уңаеннан, 2–19 июнь көннәрендә Чаллы шәһәренең «Саулык» балалар лагеренда Луганск Халык Республикасының Лисичанск шәһәреннән 139 бала ял итә.

Салкынча

Бу атнада Татарстанда салкынча һава торышы саклана. Урыны белән яшенле яңгыр һәм көчле җил булырга мөмкин.

Гидрометеоүзәк хәбәр иткәнчә, чәршәмбе – 7 июньдә республикада явым-төшем көтелми диярлек. Көндез термометрның терекөмеш баганасы +19…+24, төнге сәгатьләрдә +6…+12 градус күрсәтәчәк. Пәнҗешәмбе – 8 июньдә көндез һава температурасы +19…+24 градус чикләрендә тирбәләчәк. Урыны белән яшенле яңгыр, көчле җил көтелә. Төнлә асылда явым-төшемсез, +7…+12 градус.

Синоптикларның башлангыч мәгълүматлары буенча, 9, 10 июнь – җомга һәм шимбә көннәрендә салкынча һава саклана. Көндез +18…+23 градус. Урыны белән явым-төшем булырга мөмкин.

Сүз уңаеннан, республика урманнарында янгын куркынычы зур булу сәбәпле, кисәтү игълан ителгән. Метеорологлар билгеләп үткәнчә, 6–12 июнь чорында Татарстанның кайбер районнары урманнарында югары (4 класс) һәм гадәттән тыш югары дәрәҗәдә (5 класс) янгын куркынычы сакланачак.

Сак булыгыз!

Гомер түгел, су аксын

Кояш ныграк кыздырган саен, аяклар су буена тарта. Әмма бәла дә шул аяк астында бит. Җәй җиткәч, сулыкларда батып үлүчеләр турында ешрак ишетә башлыйбыз. Кызганыч, ел башыннан андыйларның саны 12гә җитте инде.

Сулыклардагы һәм су коену өчен махсуслаштырылган урыннардагы куркынычсызлык мәсьәләсен Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов та күтәрде. Хөкүмәт йортында узган утырышта иминлеккә аерым игътибар бирергә кушты Рәис. Аңлату эшләрен алып бару да, куркынычсызлыкны тәэмин итү дә керә бу мәсьәләгә.

– Халыкның җәйге ял чоры башланды. Ел башыннан сулыкларда 12 кешене югалттык. Шулар арасында ике бала да бар. Республикада 53 комлык исәпләнә. Шуларның 26сы кешеләр өчен ачык, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Чәчтараш булып эшләүче Оксана 5 яшьлек чагында чактан гына суга батып үлми. «Әбиләремдә кунакта чак иде бу. 5 яшьлек бала-чаганың өйдә олылар белән утырасы килми, билгеле. Чыгып киткәнмен инде. Йөри торгач, күлгә кадәр барып җиткәнмен. Әбиләрнең бакчасыннан ерак түгел иде ул», – дип сөйли балачагының бик үк күңелле булмаган бер көне турында ул.

Яңгыр явып киткән генә була. Күл буендагы басманы да яңгыр чылаткан. Бәләкәй Оксанага күлгә егылып төшәр өчен шул да җитә. «Кечкенә бала өчен күл шактый тирән саналгандыр инде. Курка, борчыла, кычкыра башладым. Ничек тончыкмаганмындыр? Әнинең йөгереп килеп, таш кебек катып калуын хәтерлим. Ул да курыккандыр инде. Мин аңыма килгәндә мине ярга тартып чыгарганнар иде инде. Судан әле дә куркам. Аз-маз йөзәргә өйрәндем. Этләрчә йөзү дип атыйм мин аны.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Әмма тирәнгә кермим. Балачактагысы да гомергә сабак булды», – диде ул.

Йөзү буенча тренер Алинә Меремьянина сүзләренчә, статистика буенча балалар һәм ир-атлар суда күбрәк бата. Бала-чага артыннан ата-аналар карамаса, ир-атлар сулыкта үзләрен тиешенчә тота белмәгәнгә бата.

– Махсус җиһазландырылган сулыкларда йөзү хәерлерәк, – дип киңәш итә тренер. – Суга салмак керергә кирәк. Әгәр дә ярышу турында сүз бармый икән, суга керү өчен артык әзерлек таләп ителми. Авыр ризык ашамаска, ашказанын азык-төлек белән тутырып йөзмәскә кирәк. Суны күбрәк эчегез. Кояштан да сакланырга кирәк әле.

Ахыры 4 нче биттә >

Сүзгә-сүз

Илгиз ЗӘЙНИЕВ, драматург, режиссер, «Әкият» татар дәүләт курчак театрының сәнгать җитәкчесе:

Без юл төзүчене юл төзергә өйрәтәбез, ипи пешерүчене ипи пешерергә өйрәтәбез, театрның ничек булырга тиешлеген бөтен кеше өйрәтә инде. Шуңа комплексларыңны йөгәнләп, башта уйлап карарга кирәк. Бу урынга беркемне дә урамнан алып кереп куймаганнар.

(«Интертат»ка әңгәмәсеннән)

ТАТАРСТАНДА – КАПИТАЛЬ ТӨЗЕКЛӘНДЕРҮ

Быел Татарстанда 751 күпфатирлы йортта капиталь төзекләндерү эше алып барылачак. 55ендә эшләр тәмамланган. Хәзерге вакытта 662 йортта эш бара.

751 йорт

4 млн 487 мең кв. метр мәйдан

6 млрд 717 млн сум акча

Реклама 16+

Сөенечле хәбәр!

2023 елның 5–15 июнь көннәрендә «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» газетасына ташламалы бәядән язылып була!

П2435 җомга саны — Ташламалы бәя **444 сум 54 тиен**, гадәти бәясе – ~~512 сум 70 тиен~~

П2409 атнага дүрт тапкыр чыга — Ташламалы бәя **1051 сум 80 тиен**, гадәти бәясе – ~~1227 сум 30 тиен~~



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

СӘХНӘДӘ ЙОДРЫК СЕЛКЕП, СӘХНӘ АРТЫНДА КИЛЕШҮ

Үткән атна тарихка глобаль сәясәтнең зур шахмат тактасында диспозицияләрне үзгәртү омтылышлары белән кереп калды. Әрдоганның инаугурациясе дөньякүләм вакыйгага әйләнде. Тантанага сиксәннән артык ил лидерлары, НАТО җитәкчесе, Төрки Дәүләтләр Оешмасы, Ислам Хезмәттәшлеге Оешмасын әйдәүчеләр килде. Хәтта Әрмәнстан лидеры Пашинян да кадерле кунаклар исемлегендә иде. Сәяси күзәтүчеләр, Әрдоган чыгыш ясаганда, уң ягында – Дин эшләре идарәсе башлыгы Али Әрбаш, сулда Истанбул патриархатлыгы Архиепискобы Патриарх Варфоломей утыруына да игътибар иттеләр. Инаугурациядән соң мәйданга төрек сәясәтендә кискен үзгәрешләр булу ихтималлыгына ишарә иткән яңалык чыкты: яңа Министрлар Кабинеты игълан ителде. Төрек сәясәтенең өч гиганты – тышкы эшләр министры Мәүлүт Чавушуглу, эчке эшләр министры Сөләйман Сойлу, оборона министры Хулуси Акар яңа кабинет составында юк. Алар киләчәктә югары җитәкчелектә булырлармы, әллә пенсиягә китәрләрме – мәгълүм түгел. Разведка идарәсе башлыгы да алышынды, легендар Хакан Фидан тышкы эшләр министры вазыйфасына күчте. Генштаб башлыгы Яшәр Гюлер да бүтән кәнәфигә күчеп утырды. Ул – оборона министры. Яңа төрек гамбитының ни рәвештә буласын әлегә өзеп әйтеп булмый. Интуитив рәвештә кайбер нәрсәләрне фаразлап була ләкин. Казначылык һәм финанс министры итеп Көнбатыш инвестицияләре тарафдары Мәхмәт Шимшек куелуы акча-кредит мәсьәләләрендә җитди үзгәрешләр булачагын хәбәр итә.

Инаугурация үтеп тә бетмәде, Әрдоган НАТО генераль секретаре Столтенберг белән ябык режимда сөйләшүләр үткәрде. Швеция Әнкара куйган барлык таләпләрне дә үтәде, хәзер Әрдоган шведларның НАТО составына керүенә аяк чалмаячак, диләр. Төркиянең Көнбатышка якынаюы Украина – Россия конфликтының чишелешенә йогынты ясарга ихтимал.

Якшәмбе көнне Сингапурдагы «Шангри Ла» кунакханәсендә Куркынычсызлык буенча конференция тәгәлләнде. Сәхнәдә ике зур держава АКШ һәм Кытай вәкилләре бер-берсенә йодрык янадылар, үзара гаепләүләр ташладылар. Тын океан төбәгендә хәл, чынлап та, киеренке. Үткән атнада гына анда зур бәрелешкә китерү ихтималлыгы булган берничә куркыныч вакыйга булды. Әмма АКШ Кытайны Россиягә каршы лагерьга бик актив чакыра. Шуңа күрә аналитиклар вазгыятьне сәхнәдәге сүзләр түгел, сәхнә арты килешүләре билгеләр, диләр. Башка елларда саммитта Россия вәкилләре дә катнаша иде, быел юк. Саммитка параллель рәвештә егерме илнең иң куәтле разведка вәкилләре дә яшерен очрашу үткәрделәр. Очрашуның анысында да Россиянең Тышкы разведкасы катнаштырылмады. Шымчылар төп тема итеп Украина конфликтын алдылар. Башка елларда андый яшерен очрашудан мәгълүматлар тышка чыгарылмый иде, быел берникадәр сүзләр ишетелде. Тик объективлыгы төгәл билгеле булмагач, язмыйбыз. Бу – Россия өчен бик әйбәт сигнал түгел, шуны гына әйтә алабыз...

Россиядә

САНКЦИЯЛӘР КӨЧӘЯ ДӘ, КӨЧӘЙМИ ДӘ

Мәгълүмат кырында Россия өчен яхшы хәбәрләр дә, начарлары да җитәрлек. Путин Әрдоган тантанасына бармады. Ул хәзер, гомумән, күзгә-күз очрашуларга караганда, онлайн форматны яратарак төшә. Шулай да төрек лидеры янына бер-бер артлы Путин да, Зеленский да барып кайтыр, диләр.

«Российская газета» үзенең сайтында Оборона министрлыгының Украина Кораллы көчләре 4 июньдә фронтның биш урынында зур масштаблы һөҗүм башладылар дигән хәбәрен урнаштырды. Рәсми хәбәр, украиннарга уңыш елмаймады, дигән фикерне алга сөрә. Ике як та алдырып китә алмый әлегә. Һәр ике як каршы тарафның зур югалтуларын саный. Планетадаш дәүләтләр һәркайсы диярлек конфликтны хәл итүнең үз рецептын тәкъдим итә. Ике якны да канәгатьләндерә торган формуланы гына табып булмый.

Көнбатыш дәүләтләре Россиягә каршы санкцияләрне бозучыларга санкцияләр кертү белән мәшгуль. Санкцияләр баба шулпасының шулпасына әверелеп бара бугай инде. Юк, юк, без алардан берниндиә дә зыян юк дип әйтмибез. Бар һәм ничек кенә бар әле. Әмма Көнбатыш теләгән нәтиҗәләр барыбер юк. Глобаль бизнес үзен тышаулаганны бер дә яратмый. Ул аның яшәешенә туры килми чөнки. Хәтта дошман илләр дә үз эшмәкәрләрен Россия белән хезмәттәшлек итүдән тыеп бетерә алмыйлар. Яшерен рәвештә Россия бизнесы белән кул кысышучылар җитәрлек. Европаның зур сәясәтчеләре дә моны аңлый хәзер. Евросоюзның лидерларыннан берсе Жозеп Боррель үткән атнада Россиягә каршы санкцияләр бары тик Европа Союзының икътисадый операторларына гына карый, өченче илләр моңа мәҗбүр ителми, Көнбатыш ул илләрнең лидерлары белән конфликттан сакланырга тиеш, дигәнрәк белдерү ясады. Кыскасы, Боррель фикеренчә, Казахстан, Әрмәнстан, Берләшкән Гарәп Әмирлекләре, Төркия кебек илләрнең Россиягә параллель импортны әйләндерүче тәгәрмәчләренә күсәк тыгылмаячак. Дөрес аңлагыз: Көнбатыш кертелгән санкцияләрне үтәтүдән баш тартмый, хәтта кырысрак та булырга тырыша, ләкин таякны бөтенләй үк бөгеп тә ташлый алмый, чөнки үзе дә зур зыян күрә. Әйтик, мәсәлән, «Шкода» гына да Россия базарыннан китеп, 2022 елда ярты табышын югалткан. Югарыдагы сүзләрне Боррельның шәхси фикере генә дип тә аңлый аласыз, әмма ул гомуми кәефне чагылдыра.

Санкцияләр безнең өчен дә бик татлы түгел. «Российская газета» әнә «Стоимость товаров из Китая растет из-за большого спроса» дигән баш астында язма бирә. «Спрос» алай зур булмас иде, Көнбатыштан товар агымнары саекты. Кытайдан товар ташу да кыйммәткә төшә, чыгымнары зур. Монополистка әверелгән чиннар үз кагыйдәләрен рәхәтләнеп тагалар, анысы да бар.

УРТАК ЙОРТ

Татарстанда барлык милләтләрне дә хөрмәт итәләр. Бу хакта Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов республиканың Рус милли-мәдәни берләшмәсе вәкилләре белән очрашу барышында әйтте.

Республика җитәкчесе аларга башкарган эшләре өчен рәхмәт җиткерде.

– Сезнең барлык проектларыгыз да чынга аша. Узган елгы очрашу нәтиҗәләре турында беләбез, бик күп эш башкарылган. Быелгы «Каравон» бәйрәме дә уңай тәэсирләр генә калдырды, – диде ул.

Рус милли-мәдәни берләшмәсе җитәкчесе Ирина Александровская сүзләренә караганда, Рөстәм Миңнехановның иҗат интеллигенциясе белән очрашуы күркәм традициягә әверелгән.

– Сезнең игътибарыгыз шәһәребезгә, республикабызга үсәргә ярдәм итә. Бүген күп кенә проектлар тормышка ашырылды, – диде ул.

Ирина Александровская Рус милли-мәдәни берләшмәсенең моннан нәкъ ун ел элек оешуын да искә төшерде.

– Сезнең ярдәмегез белән Татарстанда шактый эш башкарылды. Изге Петр һәм Февронииягә һәйкәл ачылды. Дүрт ел элек Пушкин исемендәге мәдәни үзәк эшли башлады. Рус милли-мәдәни берләшмәсенең ресурс үзәге оешты, – диде ул.

Форсаттан файдаланып, берләшмә вәкилләре Рәискә үзләрен борчыган мәсьәләләр турында да җиткерде. Аерым алганда, чарада Чистай музее хезмәткәрләренең белемен арттыру, халык биюләре, җырлары, уеннары, бәйрәмнәре һәм йолаларына бәйле материалларны системалаштыру, Казан рус фольклоры үзәгенә аерым бина бүлеп бирү турында сөйләштеләр. Рөстәм Миңнеханов очрашуда яңгыраган барлык сорауларны игътибарга алырга вәгъдә итте. Мәсәлән, Казан рус фольклоры үзәген биналы итү өчен якын арада ук шәһәр хакимиятенә мөрәҗәгать итәчәкләр.

– Без барлык милләт халыкларын, барлык диннәрне һәм телләрне хөрмәт итәбез. Шул ук вакытта, рус теленә аерым игътибар булырга тиеш. Ул – дәүләтебезнең төп теле һәм бу хакта сөйләшеп тору да артык, – диде Рәис.

tatarstan.ru

Казанда опера җырчысы Федор Шаляпин һәм язучы Максим Горькийга багышланган мемориаль композиция ачылды. Тантаналы чарада Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов катнашты. Рәис сүзләренә караганда, Горький һәм Шаляпин бер-берсен бертуганнар дип атап йөрткәннәр. Аларны сәнгатькә, Ватанга һәм аның сәләтле халкына мәхәббәт берләштергән. «Казанда алар рухи үсешкә ирешге. Бүген әлеге ике талантлы шәхес кабат бергә», – диде Рәис. Мемориаль комплекс М.Горький һәм Ф.Шаляпин музейлары диварында урнаштырылган. Язучы бюсты бу бинада 1967 елда ук лаеклы урын алган иде инде. Хәзер диварны опера җырчысы бюсты һәм Казан күренеше дә бизәп торачак.

РУС ДӨНЬЯСЫНЫҢ БЕРЛӘШҮ ТЕЛЕ

Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм МИҢНЕХАНОВның Рус теле көнен һәм А.С. Пушкинның тууына 224 ел тулуны бәйрәм итү уңаеннан МӨРӘҖӘГАТЕ

Хөрмәтле татарстанлылар!

Сезне Рус теле көне уңаеннан ихлас йөрәктән тәбрик итәм. Без бу бәйрәмне традицион рәвештә даһи әдип Александр Сергеевич Пушкинның туган көнендә уздырабыз.

Аның әсәрләрендә рус теленең байлыгы, аһәңе, образлылыгы, камиллеге һәм чын матурлыгы күркәм чагылыш таба, халык сөйләменең, үзенчәлекле фольклорының зирәк, үткен гыйбарәләре гаҗәеп зур осталык белән нәфис әдәбият үрнәге югарылыгына күтәрелә.

Александр Сергеевич илебезнең күп кенә халыклары рухи мирасын бөтен нечкәлекләре белән өйрәнеп, алардан илһам алган. Шуңа да шагыйрьнең бай иҗаты Россия халыклары традицияләренә аваздаш, уртак Ватанга мәхәббәт, тарихи тамырларыбызга олы хөрмәт белән сугарылган. Татарстанда игълан ителгән Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елында аның күпкырлы эшчәнлегенең шушы сыйфаты турында аеруча зур ихтирам белән сөйлибез.

А.С. Пушкинның: «Намусым белән ант итәм, ни генә вәгъдә итсәләр дә, мин Ватанымны алыштырырга яисә Илаһ безгә насыйп иткән тарихтан үзгә тарихка ия булырга теләмәс идем», – дигән сүзләренең тирән мәгънәсе хәзерге чорда яңача ачыла. Без Россия халыкларының бай мирасы, ата-бабаларыбызның данлы тарихы белән горурланабыз һәм аларның лаеклы дәвамчылары булырга телибез.

Рус теле бүгенге көндә халыкара элемтәләрнең төрле өлкәләрендә хаклы төстә күренекле урын тота, «рус дөньясы»ның берләшүенә ярдәм итә. Ул, һичшиксез, төрле милләт вәкилләренең аралашуы, аңлашып яшәве, бер-берсенең асылына төшенүе өчен гаять мөһим чара булып тора, ә болар исә Туган илебездә тынычлыкны, татулыкны саклауга һәм ныгытуга ныклы нигез хезмәтен үти.

Бәйрәм мөбарәк булсын! Сезгә чын күңелдән сәламәтлек, игелекле омтылышлар һәм хәерле эшләр телим!

Күрәләр, ишетәләр

Татарстан Дәүләт Советы илнең иң ачык төбәк парламенты дип танылды. Төбәк закон чыгару органнарының Бөтенроссия бәйсез тикшеренүе барышында белгечләр шундый нәтиҗәгә килгән. Алар илнең 85 төбәген өйрәнгән.

Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин фикеренчә, Татарстанда хакимиятнең ачыклыгы мәсьәләләренә зур игътибар бирелә. Парламент башлыгы төбәк органнарының ачык булуын закон чыгару органнарының нәтиҗәлелеген бәяләүнең иң мөһим критерийларының берсе дип саный. «Закон чыгару эшчәнлегеннән тыш, депутатларның сайлаучылар белән элемтәсе, шул исәптән халыктан килгән мөрәҗәгатьләр белән эшләве дә мөһим», – ди Фәрит Мөхәммәтшин.

Илнең иң ачык төбәк парламентын ачыклар алдыннан белгечләр аларның парламент, комитет һәм комиссия утырышларын турыдан-туры трансляцияләүне ни дәрәҗәдә оештыруын, видеоархивларны ачык куллану мөмкинлеген тудыруларын өйрәнгән, социаль челтәрләрдәге эшчәнлекне дә исәпкә алган. Моннан тыш алар кертелгән һәм кабул ителгән закон проектларының басылуын һәм эш барышы турында мәгълүматны тикшергәннәр. Белгечләр төрле каналлар, телефон, электрон почта, парламентның электрон формасы, социаль челтәрләр аша аралашу һәм элемтәне дә бәяләгән.

Парламентларның ачыклыгы рейтингы Санкт-Петербургның «1870» шәһәр үзидарәсен үстерү фонды тарафыннан булдырылган. Фонд «Парламент – уч төбендә» тикшеренүен өченче тапкыр үткәрә. Алдагылары 2020 һәм 2021 елларда үткәрелгән булган.

ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ДЕПУТАТЛАРЫ ИГЪТИБАРЫНА

Алтынчы чакырылыш Татарстан Дәүләт Советының кырык дүртенче утырышы 8 июнь көнне (10.00 сәгатьтә башлана) Дәүләт Советы утырышлар залында үткәрелә.

Депутатлар Дәүләт Советы бинасында 8 июньдә 8.00 сәгатьтән башлап теркәлә.

Белешмәләр алу өчен телефон: 267-63-62.

КОТЛЫЙБЫЗ!

Татарстан Республикасының сәнәгать потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен «Алабуга автомобиль заводы җитештерү берләшмәсе» акционер җәмгыяте генераль директоры **Галимов** Камил Салман улы, «Вакууммаш» акционер җәмгыяте генераль директоры **Капустин** Евгений Николаевич, «Казанның «Союз» тәҗрибә конструкторлык бюросы» акционер җәмгыяте генераль директоры **Латыйпов** Наил Шәүкәт улы, «Казан дәүләт казна дары заводы» федераль казна предприятиесе генераль директоры **Лившиц** Александр Борисович **«Дуслык» ордены** белән бүләкләнде.

* * *

Республиканың транспорт комплексын үстерүгә мөһим өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Казан шәһәре «Метроэлектротранс» муниципаль унитар предприятиесенең капиталь төзелеш бүлеге башлыгы **Груничева** Алевтина Александровна; республиканың химия сәнәгатен үстерүгә мөһим өлеш кертүе һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен Казанның «Органик синтез» гавами акционер җәмгыятенең баш инженеры хезмәте ремонтлау производствосының механика юнәлеше полимерлар, сополимерлар төп производствосы технологик җиһазларына техник хезмәт күрсәтү һәм төзекләндерү буенча 9 номерлы участогының 2 номерлы төркеме слесарь-ремонтчысы **Козарев** Николай Алексеевич; республикада автомобиль спортын популярлаштыруга мөһим өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Татарстан Республикасының автомобиль спорты федерациясе» төбәк иҗтимагый оешмасы җаваплы секретаре **Рамазанов** Радик Вахит улы; законлылыкны ныгытуга, гражданнарның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклауга мөһим өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Югары Суды судьясы **Фәхриев** Марсель Мансур улы **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале** белән бүләкләнде.

* * *

«Аксубай авылара үзәк китапханәсе» район муниципаль бюджет мәдәният учреждениесенә хезмәт күрсәтү бүлеге мөдире **Гатина** Фәимә Гариф кызына, «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының үзәкләштерелгән китапханә системасы» муниципаль бюджет учреждениесе директоры **Дугаева** Наталья Сергеевнага, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Әгерҗе үзәкләштерелгән клуб системасы» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесенең 1 номерлы секторы – Бима авылы мәдәният йорты мөдире **Корнев** Владимир Ивановичка, Чаллы шәһәренең «Чишмә» халыклар дуслыгы йорты» муниципаль автоном мәдәният учреждениесенең вокалчы артисты (солисты) **Сидорова** Валентина Капитоновнага, Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Бөгелмә балалар сәнгать мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү мәгариф учреждениесенең аккордеон классы буенча укытучысы **Скитина** Людмила Евгеньевнага, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының «Зәй балалар музыка мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесенең махсус фортепиано укытучысы **Тимофеева** Татьяна Александровнага, «Әлки район мәдәният йорты» муниципаль бюджет учреждениесенең үзешчән театр коллективы режиссеры **Шиһапова** Эльмира Николаевнага, Чистай муниципаль районының «С. Гобәйдуллина исемендәге балалар сәнгать мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү оешмасының тынлы уен кораллары классы буенча укытучысы **Шляхтин** Вадим Михайловичка **«Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Казан шәһәре Мәскәү районының «М.С. Устинова исемендәге 102 номерлы гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең рус теле һәм әдәбияты укытучысы **Боженко** Ольга Сергеевнага, Казан шәһәре Киров районының «Аерым фәннәр тирәнтен өйрәнелә торган 151 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең рус теле һәм әдәбияты укытучысы **Родионова** Евгения Борисовнага, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының «Яңа Бүләк төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең рус теле һәм әдәбияты укытучысы **Сәлахова** Флюра Рәфхәт кызына, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Мүлмә урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең рус теле һәм әдәбияты укытучысы **Сәлахова** Һиндия Һидият кызына, Казан шәһәре Мәскәү районының «94 номерлы гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең рус теле һәм әдәбияты укытучысы **Сәфәрова** Ләлә Зәкәрия кызына, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Мөслим лицее муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең рус теле һәм әдәбияты укытучысы **Хәлиуллина** Луиза Исмәгыйль кызына, Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының 2 номерлы лицее муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең рус теле һәм әдәбияты укытучысы **Щербинина** Светлана Александровнага **«Татарстан Республикасының атказанган укытучысы»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесе Халыкара мөнәсәбәтләр институтының Тарих фәннәре һәм бөтендөнья мәдәни мирасы югары мәктәбе антропология һәм этнография кафедрасы доценты **Гущина** Елена Геннадьевнага **«Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

САЛЫМ КИМИ

Ике һәм аннан да күбрәк бала тәрбияләүче гаиләләрне йорт урнашкан җир һәм андагы хуҗалык корылмаларын сатканда салым түләүдән азат иттеләр. Моңарчы мондый ташламадан фатир һәм йорт сатучы әти-әниләр генә файдалана ала иде. Җир салымына бәйле башка үзгәрешләр дә бар.

Узган атнада Россия Президенты Владимир Путин ике һәм аннан да күбрәк бала тәрбияләүче гаиләләрне йорт урнашкан җир һәм андагы хуҗалык корылмаларын саткандагы керемгә салым түләүдән азат итүгә бәйле канунны имзалады. Документтан аңлашылганча, яңалык 18 яшькә кадәрге (көндезге бүлектә укыган очракта, 24 яшькә кадәр) бала тәрбияләүче әти-әниләргә кагыла. Шунысы да бар: сатудан кергән акча шул ук елны яңа милек сатып алуга тотылырга тиеш. Моңарчы ике һәм аннан да күбрәк бала тәрбияләүче гаиләләр фатир яки йорт сатканда гына мондый ташламадан файдалана ала иде. Ә менә йорт урнашкан җир кишәрлеге һәм бирелдәге хуҗалык корылмаларыннан алган керемгә барыбер салым түләргә туры килде.

– Яңа канун яшәү шартларын яхшыртырга теләүче гаиләләргә ярдәм итәчәк, – ди икътисад белгече Илдус Сафиуллин. – Ишле гаиләдә болай да акчаның һәр тиене исәптә. Керемгә салымнан азат итү торакны зуррагына алмаштырырга берникадәр этәргеч тә бирәчәк.

Белгечләр агымдагы елда салым түләүгә бәйле үзгәрешләр турында да искә төшергән. Билгеле булганча, җир кишәрлекләре хуҗалары ел саен милек өчен салым түли. Ул һәр елның 1 гыйнварына «Росреестр»га кертелгән дәүләт кадастр бәясеннән чыгып исәпләнә. Быел әнә шул саннар үзгәргән. Эш шунда ки: былтыр ил күләмендә җирләргә дәүләт кадастр бәяләве үткәрелде. Бу исә – түләүләрдә дә чагылырга мөмкин дигән сүз. Тик республикада яшәүчеләрне тынычландырганнар.

– Татарстанда яңача исәпләнгән җир салымы халыкка 2025 елда гына киләчәк. 2023 ел өчен җир салымы гамәлдәге кадастр бәясе буенча саналачак, – дип ачыклык керткән «Росреестр»ның Татарстандагы идарәсенең милеккә кадастр бәяләве бүлеге җитәкчесе Татьяна Надысева.

Белгеч сүзләренә караганда, кадастр бәясе милеккә салым, дәүләт пошлинасы (мәсәлән, милекне мирас итеп кабул итеп алганда), җир кишәрлегеннән файдаланганда аренда хакы кебек түләүләрне билгеләү өчен файдаланыла. Базар бәясеннән аермалы буларак, ул – гомуми күрсәткечләрдән чыгып исәпләнә. Мәсәлән, кадастр бәясен ачыклаганда фатирдагы ремонтның булу-булмавы, тәрәзәләрнең елга ярына яки урманга карап торуы исәпкә алынмый. Милеккә кадастр бәясе турындагы мәгълүматны Дәүләт хезмәтләре порталы яки «Росреестр»ның рәсми сайтындагы шәхси кабинет аша алырга мөмкин. Әлеге хезмәт бушлай.

Эльвира ВӘЛИЕВА

Илдар Мөхәммәтҗанов

Сан

Бу елның марты белән чагыштырганда, апрельдә Татарстанда җир кишәрлекләренә сорау 48,8 процентка арткан. Шәхси торак йортларны – 35 процентка, фатирларны – 29, торак булмаган биналарны 28 процентка күбрәк сатып алганнар. Апрельдә икенчел торак базарында сату-алулар саны 38 процентка диярлек үскән. Бер ай эчендә 21 меңгә якын килешү теркәлгән. Узган елның шушы ук чоры белән чагыштырганда, бу – 22 процентка күбрәк.

(«Росреестр»ның Татарстандагы идарәсенең матбугат хезмәтеннән)

ҖӘЙГЕ «НӘҮРҮЗ»

Фестиваль

1000нән артык катнашучы, 29 театр коллективы һәм шуның кадәр үк спектакль. Казанда төрки халыкларның XVI «Нәүрүз» Халыкара театр фестивале башланды. Төрки халыклар театрларын берләштерә торган мәдәни чара Казанда 5–11 июньдә узачак.

Россия төбәкләре театрлары арасында элемтәләрне үстерү һәм ныгыту максатыннан үткәрелгән фестиваль быел Төньяк Кавказ халыкларының театр сәнгатенә багышлана. Фестивальнең репертуары үзенең төрлелеге белән аерылып тора: монда чит ил классикасы да, эпослар да, заманча драматургия дә бар.

Чара 1000нән артык катнашучыны җыячак. Анда Төркия, Казахстан, Үзбәкстан, Кыргызстан һәм Россиянең бик күп төбәкләре – Төньяк Осетия-Алания, Адыгея, Дагыстан, Чечен, Кабардино-Балкария, Чувашия, Башкортстан, Саха, Алтай, Тыва һәм Татарстан театрлар коллективлары катнаша. Фестиваль кысасында тамашачыларга 29 спектакль тәкъдим ителәчәк.

Татарстанның мәдәният министры урынбасары Дамир Натфуллин әлеге фестивальгә кызыксыну һәрвакыт зур булуын әйтте.

– Мин моны бүген очрашуга килгән журналистлар саны буенча да әйтә алам. «Нәүрүз» ул – республикада һәм якын төбәкләрдә генә түгел, Россиянең иң ерак төбәкләрендә һәм БДБ илләре киңлегендә мөһим вакыйга, – диде ул матбугат очрашуында. – Быел республикада игълан ителгән Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елында әлеге фестивальнең әһәмияте тагын да арта. «Нәүрүз» ул – беренче чиратта, аралашу. Актер белән тамашачы, тәнкыйтьчеләр, актерларның үзара аралашуы. Мәдәният ул – безне һәм күрше төбәкләребезне бәйли торган җеп. Әлеге фестиваль Казан халкына һәм меңләгән туристларга башка төбәкләрнең мәдәниятенә кагылу мөмкинлеге бирә.

Фестивальнең сәнгать җитәкчесе, Камал театрының баш режиссеры Фәрит Бикчәнтәев фестивальнең юбилей елы булуын искәртте.

– «Нәүрүз» фестивале Казанда 25 ел элек барлыкка килде. Бүген фестиваль Россиянең мәдәни картасында зур әһәмияткә ия. Без аны илебез өчен катлаулы вакытта да уздыру җаен таптык. Моның өчен республика җитәкчелегенә зур рәхмәт. Һәр фестивальне, гадәттә, билгеле бер төрки халык мәдәниятенә багышлыйбыз. Бу юлы Төньяк Кавказ халыклары театр сәнгатенә мөрәҗәгать итәргә булдык. Бу – үзенчәлекле һәм кызыклы театр коллективларына бай як, – диде Фәрит Бикчәнтәев.

Фестивальнең махсус кунагы – Мәскәүнең «Драма сәнгате мәктәбе».

– Безнең өчен «Нәүрүз» фестивалендә катнашу – зур дәрәҗә. Быел икенче тапкыр катнашабыз. Бу юлы бөек драматург Чеховның «Вишневый сад» спектаклен алып килдек. Шәхсән минем һәм театр өчен бик әһәмиятле спектакль. Чеховның соңгы пьесасында анын васыяте бар кебек, – диде «Драма сәнгате мәктәбе» сәнгать җитәкчесе Игорь Яцко.

Төньяк Кавказ театрлары берлеге җитәкчесе, Горький исемендәге рус драма һәм Салаватов исемендәге кумык театры директоры Искәндәрбек Тулпаров Төньяк Кавказ театрларына игътибар биргәне өчен фестиваль җитәкчелегенә рәхмәтен җиткерде.

– Минемчә, бу – бик мөһим һәм дөрес идея. Гадәттә, Төньяк Кавказ театрлары үз тормышы белән яши. Аларны да мәдәни аралашу киңлегенә җәлеп итәсе иде, – диде ул.

«Нәүрүз» фестиваленең спектакльләре Камал театрының һәм «Әкият» курчак театрының Зур һәм Кече сәхнәсендә, Тинчурин, Кариев исемендәге һәм Казан яшь тамашачылар театрларында күрсәтеләчәк.

Ләйсән САФИНА

КОМПЛЕКСЛЫ КАДАСТР ЭШЛӘРЕН БАШЛАП ҖИБӘРҮ ТУРЫНДА ХӘБӘРНАМӘ

2023 елның 6 мартыннан 2023 елның 15 ноябренә кадәрге чорда, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан түбәндәге күчемсез милек объектларына карата:

– Биектау муниципаль районы, Биектау авыл җирлеге (кадастр кварталлары № 16:16:081001, 16:16:082101, 16:16:083201, 16:16:190701);

– Биектау муниципаль районы, Дачное авыл җирлеге (кадастр кварталлары № 16:16:213101);

– Биектау муниципаль районы, Красносельский авыл җирлеге (кадастр кварталлары № 16:16:081601);

– Биектау муниципаль районы, Семиозерка авыл җирлеге (кадастр кварталлары № 16:16:211801, 16:16:212301, 16:16:212401, 16:16:211701);

– Биектау муниципаль районы, Усад авыл җирлеге (кадастр кварталлары № 16:16:172101, 16:16:172301);

– Биектау муниципаль районы, Чыпчык авыл җирлеге (кадастр кварталы № 16:16:181301);

– Биектау муниципаль районы, Чернышевский авыл җирлеге (кадастр кварталлары № 16:16:321001, 16:16:321201);

– Яшел Үзән муниципаль районы, Осиново авыл җирлеге (кадастр кварталлары № 16:20:080105, 16:20:080107, 16:20:080110, 16:20:080202);

– Питрәч муниципаль районы, Кощаково авыл җирлеге (кадастр кварталлары № 16:33:080301)

06.03.2023 № 923000033-ОК Дәүләт контракты нигезендә, комплексы кадастр эшләре башкарылачак. Заказчысы – Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы, почта адресы: Татарстан Республикасы, Казан ш., Вишневский ур., 26 й., элемтәгә керү өчен телефон: 8 (843) 221-40-60.

1. Комплексы кадастр эшләрен башкаручы кадастр инженеры:

Фамилиясе, исеме, атасының исеме: Елесин Роман Николаевич.

Адресы: 420071, ТР, Казан ш., Парк ур., 10 й., 39 кв.

Электрон почта адресы: filial@16.kadastr.ru.

Элемтәгә керү өчен телефоны: (843) 514-90-77 (өстәмә номер 2472).

Квалификацион аттестаты: идентификация номеры: 16-14-698, бирү датасы: 26.05.2014 ел.

Кадастр инженеры әгъза булып торган, кадастр мөнәсәбәтләре өлкәсендәге үзкөйләнешле оешма атамасы: «АКИ Поволжье» үзкөйләнешле оешмасы» ассоциациясе, реестрдагы номеры 30838.

Кадастр инженеры килешү төзеп, шуның хезмәткәре булып торган юридик зат атамасы: «Роскадастр» гавами-хокукый компаниясенең Татарстан Республикасы буенча филиалы.

2. «Күчемсез милекне дәүләт теркәвенә алу турында» 13 июль, 2015 ел, № 218-ФЗ Федераль законның 69 статьясындагы 4 өлеше нигезендә элек исәпкә алынган дип саналган яки үзе турында мәгълүматлар «Күчемсез милекне дәүләт теркәвенә алу турында» 13 июль, 2015 ел, № 218-ФЗ Федераль законның 69 статьясындагы 9 өлеше нигезендә, Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрында күчемсез милекнең мондый объектлары турында мәгълүматлар булмаган очракта, элек исәпкә алынган буларак Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрына кертергә мөмкин булган күчемсез милек объектлары хуҗалары комплексы кадастр эшләрен башлап җибәрү турында хәбәрнамәнең 1 пунктында күрсәтелгән кадастр инженерына – комплексы кадастр эшләрен башкаручыга мондый күчемсез милек объектларына карата үзендә булган материаллар һәм документларны, шулай ук «Күчемсез милекне дәүләт теркәвенә алу турында» 13 июль, 2015 ел, № 218-ФЗ Федераль законның 21 статьясындагы 1 һәм 9 өлешләрендә билгеләнгән тәртиптә расланган, әлеге күчемсез милек объектларына хокукны билгеләүче яки раслаучы документлар күчермәләрен тапшыруга хокуклы.

3. Күчемсез милек объектлары – җир кишәрлекләре, биналар, корылмалар, төгәлләнмәгән төзелеш объектлары хуҗалары комплексы кадастр эшләрен башлап җибәрү турында хәбәрнамә басылып чыккан көннән соң утыз эш көне эчендә 1 пунктта күрсәтелгән кадастр инженерына – комплексы кадастр эшләрен башкаручыга комплексы кадастр эшләрен башлап җибәрү турында хәбәрнамәнең 2 пунктында күрсәтелгән, күчемсез милек объектына хокуклы булуы теркәлгән зат белән элемтәгә керү өчен электрон почта адресы һәм (яки) почта адресы турында мәгълүматлар күрсәтелгән адрес буенча – күчемсез милек объектына хокукы теркәлгән зат белән, шулай ук үз файдасына күчемсез милек объектына карата чикләү салынган зат белән элемтә алып барыла торган – объект хуҗасының элемтәгә керү өчен адресы турында мәгълүматларны Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрына кертү өчен һәм мондый затларга комплексы кадастр эшләре нәтиҗәләре буенча территориянең карта-планы проектын әзерләүне төгәлләү турында һәм җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү мәсьәләсе буенча килештерү комиссиясе утырышын үткәрү турында мәгълүматларны тапшырырга тиеш.

4. Комплексы кадастр эшләре территориясендә урнашкан күчемсез милек объектлары хуҗалары комплексы кадастр эшләрен башкаруга комачауламаска тиеш, һәм алар комплексы кадастр эшләрен башкаручыга билгеләнгән вакыт графигы нигезендә әлеге күчемсез милек объектларына үтүен тәэмин итүгә бурычлы.

5. Комплексы кадастр эшләрен башкару графигы

№	Датасы һәм сроклары	Эшләр
	Әзерлек этабы	
1.1	Контракт төзелгәннән соң 10 (ун) эш көне эчендә	1. Комплексы кадастр эшләрен башлап җибәрү турында хәбәрнамә юллана (Заказчы, Эш башкаручы). 2. Эш башкаручы башлангыч мәгълүматларны җыя һәм анализлый.
1.2	Контракт төзелгәннән соң 20 (егерме) эш көне эчендә	1. Килештерү комиссиясе булдырыла. 2. Эш башкаручы комплексы кадастр эшләре башкарылачак территорияне карап чыга.
1.3	Хәбәрнамә басылып чыккан көннән соң 30 (утыз) эш көне эчендә	1. Эш башкаручы комплексы кадастр эшләре территориясендә геодезия эшләрен башкара. 2. Эш башкаручы элек исәпкә алынган мәгълүматларны хокукларны теркәү органына кертү турында гариза тапшыра. 3. Эш башкаручы күчемсез милек объектлары хуҗаларыннан аларны теркәү адреслары турында мәгълүматлар һәм күчемсез милек объектлары турында документлар җыя. 4. Эш башкаручы картографик материаллар куллану нигезендә төзелгән җир кишәрлекләре чикләре схемасын әзерли һәм аны Заказчыга җибәрә. 5. Эш башкаручы хокукларны теркәү органына күчемсез милек объектына хокукы теркәлгән зат белән, шулай ук күчемсез милек объектына хокукка чикләү салынган зат белән элемтә алып бару өчен электрон почта адресы һәм (яки) почта адресы (алга таба – милеккә хокуклының адресы һәм (яки) милеккә хокуклының электрон почта адресы) турында мәгълүматлар тапшыра.
2.	**1 этап**	1. Эш башкаручы күчемсез милек объектларын тикшерә, күчемсез милек объектлары характеристикаларын билгели, күчемсез милек объектларының урнашу урынын билгели. 2. Эш башкаручы күчемсез милек объектлары чикләренең урнашу урыннары нокталары координатларын билгели. 3. Эш башкаручы территориянең карта-планнары проектын әзерли. 4. Эш башкаручы, «Личный кабинет кадастрового инженера» сервисы ярдәмендә территориянең карта-планнарының закон таләпләренә туры килүен тикшерә.
3.	**2 этап**	
3.1		1. Эш башкаручы территориянең әзерләнгән карта-планнары проектларын Заказчыга карап тикшерүгә җибәрә. 2. Заказчы территориянең карта-планнары проектларын килештерү комиссиясенә җибәрә. Килештерү комиссиясе утырышы үткәрелә, шул исәптән эш башкаручы катнашында.
3.2	Килештерү комиссиясенең беренче утырышыннан соң 35 (утыз биш) эш көне эчендә.	Килештерү комиссиясенә җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынына карата каршы килүләр җибәрелә.
3.3	5 эш көне эчендә	1. Эш башкаручы килештерү комиссиясенең эш нәтиҗәләре буенча эшләп җиткерелгән территориянең карта-планнарының «Личный кабинет кадастрового инженера» сервисы ярдәмендә закон таләпләренә туры килүен тикшерә. 2. Территориянең карта-планнары проектларын соңгы редакциядә эшли.
4	**3 этап**	
4.1	Каршы килүләрне тапшыру срогы тәмамланганнан соң 20 (егерме) эш көне эчендә	Килештерү комиссиясе Заказчыга Эш башкаручы тарафыннан соңгы редакциядә эшләнгән территориянең карта-планнарын һәм аны раслау өчен кирәкле килештерү комиссиясе утырышы материалларын раслауга җибәрә.
4.2		Заказчы тарафыннан территориянең карта-планнары раслана.
5	**4 этап** 2023 елның 15 ноябреннән дә соңга калмыйча	1. Заказчы расланган карта-планнарны хокукларны теркәү органына җибәрә. 2. Комплексы кадастр эшләре нәтиҗәләрен кертү тәэмин ителә. 3. Эш башкаручы Заказчы исеменә башкарылган эшләр актын, 2 (ике) нөсхәдә, счет һәм счет-фактура (булганда) белән, җибәрә. 4. Заказчы башкарылган эшләр актына кул куя.

КОМПЛЕКСЛЫ КАДАСТР ЭШЛӘРЕН БАШЛАП ҖИБӘРҮ ТУРЫНДА ХӘБӘРНАМӘ

2023 елның 2 маеннан 2023 елның 15 ноябренә кадәрге чорда Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан түбәндәге күчемсез милек объектларына карата:

– Югары Ослан муниципаль районы, Түбән Ослан авыл җирлеге (кадастр кварталы № 16:15:130108);

– Биектау муниципаль районы, Биектау авыл җирлеге (кадастр кварталы № 16:16:083001, 16:16:083301);

– Биектау муниципаль районы, Усад авыл җирлеге (кадастр кварталы № 16:16:172201);

– Биектау муниципаль районы, Семиозерка авыл җирлеге (кадастр кварталы № 16:16:213301, 16:16:214301);

– Биектау муниципаль районы, Бөреле авыл җирлеге (кадастр кварталы № 16:16:230801);

– Яшел Үзән муниципаль районы, Олы Карагуҗа авыл җирлеге (кадастр кварталлары № 16:20:060101, 16:20:060103, 16:20:060104, 16:20:060105, 16:20:060106);

– Мамадыш муниципаль районы, Сөн авыл җирлеге (кадастр кварталы № 16:26:030201);

– Татарстан Республикасы, Казан ш., Совет районы (кадастр кварталлары № 16:50:140404, 16:50:140419, 16:50:140425)

02.05.2023 ел № 923000089-ОК Дәүләт контракты нигезендә, комплексы кадастр эшләре башкарылачак. Заказчысы – Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы, почта адресы: Татарстан Республикасы, Казан ш., Вишневский ур., 26 й., элемтәгә керү өчен телефон: 8 (843) 221-40-60.

1. Комплексы кадастр эшләрен башкаручы кадастр инженеры:

Фамилиясе, исеме, атасының исеме: Вәлиева Альбина Рафаил кызы.

Адресы: 420014, ТР, Яшел Үзән ш., Ленин ур., 44 й., 102 оф.

Электрон почта адресы: filial@16.kadastr.ru

Элемтәгә керү өчен телефон номеры: (843) 514-90-77 (өстәмә номер 2478).

Квалификацион аттестаты: Идентификация номеры: 16-11-266, бирү датасы: 05.03.2011 ел. Кадастр инженеры әгъза булып торган, кадастр мөнәсәбәтләре өлкәсендәге үзкөйләнешле оешма атамасы: «АКИ Поволжье» үзкөйләнешле оешмасы» ассоциациясе, реестрдагы номеры 1669.

Кадастр инженеры килешү төзеп, шуның хезмәткәре булып торган юридик зат атамасы: «Роскадастр» гавами-хокукый компаниясенең Татарстан Республикасы буенча филиалы.

2. «Күчемсез милекне дәүләт теркәвенә алу турында» 13 июль, 2015 ел, № 218-ФЗ Федераль законның 69 статьясындагы 4 өлеше нигезендә элек исәпкә алынган дип саналган яки үзе турында мәгълүматлар «Күчемсез милекне дәүләт теркәвенә алу турында» 13 июль, 2015 ел, № 218-ФЗ Федераль законның 69 статьясындагы 9 өлеше нигезендә, Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрында күчемсез милекнең мондый объектлары турында мәгълүматлар булмаган очракта, элек исәпкә алынган буларак Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрына кертергә мөмкин булган күчемсез милек объектлары хуҗалары комплексы кадастр эшләрен башлап җибәрү турында хәбәрнамәнең 1 пунктында күрсәтелгән кадастр инженерына – комплексы кадастр эшләрен башкаручыга мондый күчемсез милек объектларына карата үзендә булган материаллар һәм документларны, шулай ук «Күчемсез милекне дәүләт теркәвенә алу турында» 13 июль, 2015 ел, № 218-ФЗ Федераль законның 21 статьясындагы 1 һәм 9 өлешләрендә билгеләнгән тәртиптә расланган, әлеге күчемсез милек объектларына хокукны билгеләүче яки раслаучы документлар күчермәләрен тапшыруга хокуклы.

3. Күчемсез милек объектлары – җир кишәрлекләре, биналар, корылмалар, төгәлләнмәгән төзелеш объектлары хуҗалары комплексы кадастр эшләрен башлап җибәрү турында хәбәрнамә басылып чыккан көннән соң утыз эш көне эчендә 1 пунктта күрсәтелгән кадастр инженерына – комплексы кадастр эшләрен башкаручыга комплексы кадастр эшләрен башлап җибәрү турында хәбәрнамәнең 2 пунктында күрсәтелгән, күчемсез милек объектына хокуклы булуы теркәлгән зат белән элемтәгә керү өчен электрон почта адресы һәм (яки) почта адресы турында мәгълүматлар күрсәтелгән адрес буенча – күчемсез милек объектына хокукы теркәлгән зат белән, шулай ук үз файдасына күчемсез милек объектына карата чикләү салынган зат белән элемтә алып барыла торган – объект хуҗасының элемтәгә керү өчен адресы турында мәгълүматларны Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрына кертү өчен һәм мондый затларга комплексы кадастр эшләре нәтиҗәләре буенча территориянең карта-планы проектын әзерләүне төгәлләү турында һәм җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү мәсьәләсе буенча килештерү комиссиясе утырышын үткәрү турында мәгълүматларны тапшырырга тиеш.

4. Комплексы кадастр эшләре территориясендә урнашкан күчемсез милек объектлары хуҗалары комплексы кадастр эшләрен башкаруга комачауламаска тиеш, һәм алар комплексы кадастр эшләрен башкаручыга билгеләнгән вакыт графигы нигезендә әлеге күчемсез милек объектларына үтүен тәэмин итүгә бурычлы.

5. Комплексы кадастр эшләрен башкару графигы

№	Датасы һәм сроклары	Эшләр
	Әзерлек этабы	
1.1	Контракт төзелгәннән соң 10 (ун) эш көне эчендә	1. Комплексы кадастр эшләрен башлап җибәрү турында хәбәрнамә юллана (Заказчы, Эш башкаручы). 2. Эш башкаручы башлангыч мәгълүматларны җыя һәм анализлый.
1.2	Контракт төзелгәннән соң 20 (егерме) эш көне эчендә	1. Килештерү комиссиясе булдырыла. 2. Эш башкаручы комплексы кадастр эшләре башкарылачак территорияне карап чыга.
1.3	Хәбәрнамә басылып чыккан көннән соң 30 (утыз) эш көне эчендә	1. Эш башкаручы комплексы кадастр эшләре территориясендә геодезия эшләрен башкара. 2. Эш башкаручы элек исәпкә алынган мәгълүматларны хокукларны теркәү органына кертү турында гариза тапшыра. 3. Эш башкаручы күчемсез милек объектлары хуҗаларыннан аларны теркәү адреслары турында мәгълүматлар һәм күчемсез милек объектлары турында документлар җыя. 4. Эш башкаручы картографик материаллар куллану нигезендә төзелгән җир кишәрлекләре чикләре схемасын әзерли һәм аны Заказчыга җибәрә. 5. Эш башкаручы хокукларны теркәү органына күчемсез милек объектына хокукы теркәлгән зат белән, шулай ук күчемсез милек объектына хокукка чикләү салынган зат белән элемтә алып бару өчен электрон почта адресы һәм (яки) почта адресы (алга таба – милеккә хокуклының адресы һәм (яки) милеккә хокуклының электрон почта адресы) турында мәгълүматлар тапшыра.
2.	**1 этап**	1. Эш башкаручы күчемсез милек объектларын тикшерә, күчемсез милек объектлары характеристикаларын билгели, күчемсез милек объектларының урнашу урынын билгели. 2. Эш башкаручы күчемсез милек объектлары чикләренең урнашу урыннары нокталары координатларын билгели. 3. Эш башкаручы территориянең карта-планнары проектын әзерли. 4. Эш башкаручы, «Личный кабинет кадастрового инженера» сервисы ярдәмендә территориянең карта-планнарының закон таләпләренә туры килүен тикшерә.
3.	**2 этап**	
3.1		1. Эш башкаручы территориянең әзерләнгән карта-планнары проектларын Заказчыга карап тикшерүгә җибәрә. 2. Заказчы территориянең карта-планнары проектларын килештерү комиссиясенә җибәрә. Килештерү комиссиясе утырышы үткәрелә, шул исәптән эш башкаручы катнашында.
3.2	Килештерү комиссиясенең беренче утырышыннан соң 35 (утыз биш) эш көне эчендә.	Килештерү комиссиясенә җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынына карата каршы килүләр җибәрелә.
3.3	5 эш көне эчендә	1. Эш башкаручы килештерү комиссиясенең эш нәтиҗәләре буенча эшләп җиткерелгән территориянең карта-планнарының «Личный кабинет кадастрового инженера» сервисы ярдәмендә закон таләпләренә туры килүен тикшерә. 2. Территориянең карта-планнары проектларын соңгы редакциядә эшли.
4	**3 этап**	
4.1	Каршы килүләрне тапшыру срогы тәмамланганнан соң 20 (егерме) эш көне эчендә	Килештерү комиссиясе Заказчыга Эш башкаручы тарафыннан соңгы редакциядә эшләнгән территориянең карта-планнарын һәм аны раслау өчен кирәкле килештерү комиссиясе утырышы материалларын раслауга җибәрә.
4.2		Заказчы тарафыннан территориянең карта-планнары раслана.
5	**4 этап** 2023 елның 15 ноябреннән дә соңга калмыйча	1. Заказчы расланган карта-планнарны хокукларны теркәү органына җибәрә. 2. Комплексы кадастр эшләре нәтиҗәләрен кертү тәэмин ителә. 3. Эш башкаручы Заказчы исеменә башкарылган эшләр актын, 2 (ике) нөсхәдә, счет һәм счет-фактура (булганда) белән җибәрә. 4. Заказчы башкарылган эшләр актына кул куя

Спорт

Җавап көткәндә

Җиде кат сөйләшеп, бер кат имзалыйсы. «Ак барс» яңа сезонга әнә шундый мантыйк белән әзерләнә. Казан командасы әлегә бер генә уенчы белән килешү төзеде. Узган ел СКАда чыгыш ясаган һөҗүмче Дамир Җәгъфәров, татар телен яхшырак өйрәнү өчен, Татарстан башкаласына килә. Аннан тыш, Дмитрий Яшкин, Стивен Кэмпферны да Казанга кодалыйлар. Ә төп сорауга җавап әле дә юк: Зиннәтулла Билалетдинов калырмы?

«Ак барс» белән ЦСКА арасында хәлиткеч җиденче матч тәмамлангач, Зиннәтулла Билалетдиновтан Казанда калу-калмавы турында сорадылар. Команданы сезон уртасында кабул итеп, әйтергә кирәк, хурлыктан коткарган, аннары финалга кадәр барып җиткән баш тренер кистереп кенә берни әйтмәде. «Әлегә бу хакта сөйләшүдән мәгънә юк. Вакыт кирәк. Ял итәсем килә», – диде ул. Нәкъ бер ай узгач, Казан Кремлендә «Ак барс»ны Татарстан Рәисе кунак китте. Котладылар, рәхмәт һәм тәбрик сүзләре яңгырады. Рөстәм Миңнеханов Зиннәтулла Билалетдиновка аерым игътибар күрсәтте һәм Казанда калуын сорады. Әмма журналистлар белән сөйләшкәндә, остаз төп сорауны янә җавапсыз калдырды.

«Ак барс»ның әлегә яңа уенчылар белән килешү төзергә бик ашыкмавын әнә шул билгесезлек белән дә бәйләргә мөмкин. Казанга берничә уенчыны кодалыйлар, әмма бары берсе белән генә кул кысыштылар. Узган сезонда СКАда чыгыш ясаган Дмитрий Яшкинның Санкт-Петербургтан китүе инде төгәл билгеле. Әмма кая юл тотасы билгеле түгел. Казанга күчкән очракта ул беренче звенода чыгыш ясаган, әмма НХЛга китеп барган Дмитрий Воронковны алмаштырыр дип фаразлыйлар. Шушы көннәрдә Казан клубының америкaн сакчысы Стивен Кэмпферны чакыруы турында хәбәрләр чыкты. Ул ике ел элек «Ак барс»та уйнап киткән иде инде. 46 матчта 30 (11+19) очко җыйды. Сакчы өчен бик яхшы нәтиҗә. Сүз уңаеннан, узган сезонда «Ак барс»та бер генә чит ил уенчысы да чыгыш ясамады.

Яңа сезон алдыннан «Ак барс»ның 21 уенчы белән килешүе бар иде. Капкачы Әмир Мифтахов һәм һөҗүмче Кирилл Петров яңа килешү имзаладылар. Узган атнада алар сафына Дамир Җәгъфәров килеп кушылды. 29 яшьлек уенчы узган ел СКАда уйнады, аңа кадәр исә Түбән Новгород «Торпедо»сында танылу алды.

Дамир – Мәскәү егете. КХЛда 2012 елда чыгыш ясый башлый. Башта Новокузнецк «Металлург»ында тәҗрибә туплады. Аннары ЦСКАда, «Сибирь»дә уйнап алды. Шул арада Мәскәү командасы составында Россия чемпионы исемен яулады. Сүз уңаеннан, ул вакытта ЦСКАда Александр Радулов та уйный иде. Ике ел «Адмирал»да алка суккач, Дамир «Торпедо»га күчте. Нәкъ менә бирегә ул нәтиҗәле һөҗүмче булып танылды. Ике ел элек 58 очрашуда 61 (21+40) очко җыйды һәм Түбән Новгород командасының рекордын яңартты. Аңлашыла инде: нәтиҗәле уенчыга көчлерәк һәм баерак клублар кызыкты. Шулай итеп, егет СКАга барып эләкте. Шулай итеп, Санкт-Петербургта «татар өчлеге» барлыкка килде. Дамир Җәгъфәров ике Марат – Хәйруллин һәм Хөснетдинов белән бергә уйнады.

Татарлар димәктән, Дамир балачагында «Ак барс» өчен җан атканын искә ала. Казанга күчеп килгәч исә татар телен ныклап өйрәнмәкче. «Мин татарча беләм. Өйдә дә татарча сөйләштеләр. Авылга кунакка кайтканда бигрәк тә, – ди ул. – Казанда сөйләшүем дә яхшырыр дип уйлыйм». Бик яхшы. Әмма төп максат – күбрәк алка кертеп, командага ярдәм итү. СКАда уйнаганда бик үк килеп чыкмады. Югыйсә Санкт-Петербург клубы егетне Казанга җибәрергә җиңел генә ризалашмас иде.

СЕРЛЕ ҺӘМ СЫЙЛЫ БӘЙРӘМ

2023 ГОД НАЦИОНАЛЬНЫХ КУЛЬТУР И ТРАДИЦИЙ МИЛЛИ МӘДӘНИЯТЛӘР ҺӘМ ГОРЕФ-ГАДӘТЛӘР ЕЛЫ

Узган шимбәдә мариларның иң яраткан һәм көтеп алган Семык бәйрәме узды. Әгерҗе районының Пеләмеш авылында җәйне каршы алып, якты дөньядан киткәннәрне искә алдылар. Семык быел ничек узды? Ул нәрсәсе белән үзенчәлекле?

tatarstan.ru

Изге урынга җыелу

Семыкның тарихы славян һәм фин-угор халыкларының мәҗүси традицияләренә барып тоташа. Аны электән үк Пасхадан соң җиде атна узгач, Троица алдыннан билгеләп үткәннәр. Әүвәлге заманнарда, язгы кыр эшләре тәмамлангач, мари авылларындагы халык болынга, киртәләп алынган изге урыннарга чыккан, искә алу шәмнәре яндырган, Кирәмәткә һәм башка аллаларга корбан китергән.

Семык серлелеге белән дә үзенчәлекле. Әйтик, чәршәмбе төненнән алып пәнҗешәмбе көненә кадәр начар, явыз көчләрдән арындыру көне булып саналган. Әлеге бәйрәм җәйне каршы алуны да, якты дөньядан киткәннәрне хөрмәтләүне дә, йорт эшләрендә уңышларга ирешү өчен, әрвахлардан гафу сорауны да чагылдыра. Татарстанда яшәүче марилар бу бәйрәмнең үзенчәлекләрен бүгенгәчә саклый алган. Быел да әнә республикада яшәүчеләрне һәм Мари Эл кунакларын Пеләмеш авылында җыеп, сыйлы да, күңелле дә, мәгънәле дә бәйрәм уздырдылар.

> Әгерҗе районының Пеләмеш мари авылы Бим авыл җирлегенә карый. Пеләмешкә 1764 елда ук нигез салынган дип исәпләнә. Хәзерге вакытта монда 400ләп кеше яши.

Мари ишегаллары буйлап

Бәйрәм башланыр алдыннан, кунаклар мари халкының тарихы, яшәеше, традицияләре һәм милли сыйлары белән танышты. Махсус әзерләнгән ишегалларында XVIII–XIX гасырларга караучы милли туй киемнәрен күреп, мариларның йолаларында катнашып карарга мөмкин иде. Әйтик, бәйрәмдә катнашкан Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов, Мари Эл башлыгы Юрий Зайцев белән, теләкләрен теләп, агачка тасмалар бәйләделәр. Кунакларны аеручы «баллы» ишегалды җәлеп итте. Атамасыннан күренгәнчә, монда балдан ясалган эчемлекләр, төрле үлән кайнатмаларын авыз итеп карадылар. Ә бер почмакта кунакларны борынгы рецепт буенча куас ясарга өйрәттеләр.

Кадере арта гына

Семык – русларның Каравоны, татарларның Сабан туе, удмуртларның Гырон Быдтоны, чуаш халкының Уявы һәм мордваларның Валда Шинясе белән беррәттән халыклар арасындагы дуслыкны ныгытучы бәйрәм. Рөстәм Миңнеханов бәйрәмдә катнашучыларны әнә шулай сәламләде.

– Әлеге бәйрәм Татарстанда игълан ителгән Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елында аеруча зур әһәмияткә ия. Марилар – үз телләренә, традицияләре һәм гореф-гадәтләренә сакчыл караучы тырыш халык. Алар республика үсешенә дә зур өлеш кертәләр, безнең күпмилләтле мәдәниятебезне баеталар, – диде Татарстан Рәисе.

Ул шулай ук катлаулы чорларда традицион кыйммәтләрне – Ватанга, гаиләгә мәхәббәт, өлкәннәргә, туган телгә карата хөрмәт, төрле милләт һәм дин вәкилләренең тыныч яшәү принципларын саклауның аеруча әһәмиятле булуын искәртте.

Мари Эл башлыгы Юрий Зайцев мари халкының милли-мәдәни үзенчәлеген саклауга һәм үстерүгә зур өлеш керткәне өчен Татарстан җитәкчелегенә рәхмәтен җиткерде.

– Россиядә ярты миллионга якын мари гомер кичерә, аларның 60 проценттан артыгы Мари Эл һәм Татарстанда яши. Гомумән, Татарстан – милли үзенчәлекләрне саклау, мәдәният, тел, гореф-гадәтләр һәм йолаларны үстерү өчен барлык шартлар тудырылган күпмилләтле төбәк. Безнең республикалар арасында күп еллар буена сыналган ныклы иҗтимагый, фәнни һәм мәдәни элемтәләр бар, – диде ул, бәйрәм белән котлап.

Иртән башланган бәйрәм кич кенә тәмам булды. Ул арада «Марый патыр –2023» (мари баһадиры. – **Авт.**) һәм «Марый удыр – 2023» (мари чибәре. – **Авт.**) ачыкланды. Быел Семык бәйрәме Татарстанда 32 нче мәртәбә узды. Кунакчыл Әгерҗе районы бәйрәмне инде дүртенче мәртәбә үткәрә. Сүз уңаеннан, Татарстанда Семык 2009 елда республика халыклары бәйрәме статусы ала: тәүге тапкыр республикакүләм Семык бәйрәме 2009 елның 26 июнендә Мөслим районының Мари Бүләр авылында уза.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Семык бәйрәменә бәйле сынамышлар

✓ Семык бәйрәме көнне аяз булса, яшелчә уңа.
✓ Семык бәйрәме узуга, җеп буясаң, боз явар.
✓ Семык бәйрәменнән соң бернәрсә дә утыртырга ярамый, чөнки алар үсмәячәк.
✓ Семык бәйрәменә кадәр яланбаш йөрергә ярамый, башың авыртырга мөмкин.

Гомер түгел, су аксын

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Коткаручылар ел да суга батмас өчен нишләргә кирәклеге һәм суга батучыларга ярдәм күрсәтү кагыйдәләре турында искәртә. Без дә аларны белеп тору зыян итмәс дигән фикердә.

Суга батмас өчен:

– таныш булмаган урыннарда коенмагыз һәм суга чуммагыз;
– йөзә белмәсәгез, еракка, тирәнгә кермәгез;
– суга хәмер эчеп кермәгез.

Суга батучыга ярдәм итү өчен:

– «112» номерына шалтыратып, ярдәм чакырыгыз яисә пляждагы коткаручыларга мөрәҗәгать итегез;
– йөзә белсәгез, батучы янына килеп, су астына чумып, аның гәүдәсен арткы яктан эләктереп алыгыз. Чәченнән эләктерергә дә мөмкин;
– батучы сезнең өскә менеп, сезне дә батырырга мөмкин. Бу очракта үзегезне дә саклагыз!
– медицина ярдәменә кадәр, кешенең эчендәге суын чыгарырга, ясалма сулыш ясарга кирәк.

Белеп тор!

Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан буенча Баш идарәсе су коену рәсми төстә рөхсәт ителгән пляжлар исемлеген тәкъдим итә. Әлегә 26 пляжда су коенырга ярый.

ГАМӘЛДӘГЕ СУ КОЕНУ УРЫННАРЫ

Казанда «Комсомольское күле», «Аккош күле», «Түбән Заречье», «Тирән күл» пляжы; **Чаллыда** шәһәр, «Су анасы» пляжлары; **Түбән Кама** районында Кызыл Чишмәдә «Кама» пляжы; **Кама Аланында** «Мандарин» пляжы; Зәйдә «Зәй-2» шәһәр пляжы; **Кукмара** районында Киндеркүл авылы, Оштырма елгасының сул яры; **Чистайда** шәһәр яр буе пляжы; **Әлмәттә** шәһәр күле пляжы; **Лениногорскида** «Түбән күл» пляжы; **Бөгелмә** районында Карабаш бистәсе, «Аквапарк» пляжы; **Нурлатта** Кондырча елгасы паркындагы комлык; **Ютазы** районында Әбсәләмов бистәсендәге пляж; **Лаешта** «Кама диңгезе» пляжы; **Балык Бистәсендә** Кама елгасы янындагы пляж; **Тәтештә** Идел елгасы янындагы коену пляжы.

ЯЛ БАЗАСЫ, ШИФАХАНӘ ТЕРРИТОРИЯСЕНДӘ РӨХСӘТ ИТЕЛГӘН ПЛЯЖЛАР

Бөгелмә районында «Нептун», «Чайка», «Дружба», «Чайка 2» һәм «Ивушка» ял базасы пляжы, **Лаеш** районында «Бережок» ял базасы пляжы, **Тукай** районында «Урман әкияте» шифаханәсе пляжы.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

КОРТНЫҢ КОТЫРГАН ЧАГЫ

Абау!

Колорадо коңгызы гына җитмәгән, монысы нәрсә тагын? Узган якшәмбедә Нурлат районының Колбай-Мораса авылының бәрәңге бакчасында төшерелгән видео социаль челтәрләрне шаулатты. Андагы мыж иткән кортларны күреп, авыл халкы, бәрәңгесез калмагаек, дип борчыла. Җиләк-җимеш куакларын да баскан бөҗәкләр нинди зыян салырга мөмкин?

Башта Колбай-Морасага шалтыраттык. Мал табибы булып эшләүче Айнур Ардаширова да бакчасындагы мәхшәрне төшереп, интернетка куйган. Быел өстәвенә коңгызлары да күп икән. Борчылырсың да, авыл кешесе җәен шул бәрәңге бакчасына карап яши бит.

– Бәрәңгене 9 майда утырттык. Төбен өяргә тотынган идек, теге бөҗәкләрне шунда күрдем. Кызыл канатлы алар. Арада кара төстәгеләре дә бар. Беренче тапкыр күрүем. Нишләргә дә белми аптыраган. Бәрәңге яфрагын ашый. Очалар да килеп куналар. Колорадо коңгызы агуы сипкәч тә үлмәделәр. Күршеләрнекен белмим. Әмма каенананың бакчасында юк иде, – дип сөйләде Айнур Ардаширова.

Кичтән бик борчылган Айнур ханым иртән тынычланган иде инде. Кортлар очып киткән икән.

Кортлар турындагы видеоны газетабызның «ВКонтакте» челтәрендә дә урнаштырган идек, укучыларыбыз шактый гына фикерләр калдырган. «Нәрсә эшлисең инде? Агу сибәсең. Безнең бакчада чебен, коңгыз бар. Бәрәңгедән дүрт көн чүпләдем. Агу сиптек», – дип язган Наилә Кәлимуллина. Миләүшә апа Хузагарипова исә: «Бакчада күз ачып булмый. Бер афәттер бу», – дип борчылган.

Республика районнарына шалтыратып, вазгыятьне белештек.

Актаныш районының Куян авылында яшәүче Фәүзия Ганиева, бакчада йөргәндә, биткә килеп бәреләләр, ди. Бәрәңгеләренә кунмаганнар үзе. Мамадыштан Гөлназ Каюмова әйтүенчә, аларда корт сарымсакка ияләшкән.

Биолог-бакчачы Ризилә Гафарова да кура җиләген күреп шаккаткан. «Коточкыч күп иде», – диде. Питрәч районының Керәшен Сәрдәсе авылында яшәүче һәвәскәр бакчачы Олег Волковның мондый бөҗәкләрне беренче күрүе. Шуңа күрә көрәш чарасы турында әйтә алмады.

Арча урманчылыгының Балтач бүлеге баш урманчысы Фәргать Һадиевның бакчасын да «дус иткәннәр». Аның әйтүенчә, бу бөҗәкләр элек-электән бар. Бакча бибигонына охшаган дип фаразлады ул.

– Әмма моның кадәр котырганын күргән юк иде әле. Сливаның һәр яфрагын басканнар. Дөрес, саранча, ефәк корты кебек куркыныч түгел. Берәр нәрсә сиптер инде, диләр. Яфрак ашамый ул, борчылмагыз, дим, – ди урманчы.

КФУның зоология һәм гомуми биология кафедрасы доценты Николай Шулаев әйтүенчә, мондый хәл берничә ел элек тә күзәтелгән.

– Сабакта утыргач, кеше бәрәңгене ашап бетерә дип курка. Борчылмагыз, бернинди зыян да китермиләр, – дип тынычландыра Николай Шулаев. – Бу чебен түгел, черки. Юанаяклылар (толстоножки) дип атала ул. Алар туклана алмый. Ни өчен дигәндә, авыз аппаратлары камил түгел. Юан аяклар үзләренә кунар өчен үсемлек – бәрәңге, слива, кура һәм башка куаклар тапкан. Аларга кайда куну мөһим түгел. Бөҗәкләр яз көне, июнь башында барлыкка килә. Йомырканы туфракка салалар һәм үләләр. Берни дә сиптерергә кирәкми. Бер атнадан аларның берсе дә калмас дип уйлыйм. Икенче язга кадәр күрмәячәкбез.

Сәрия МИФТАХОВА

КОЛОРАДО КОҢГЫЗЫНА КАРШЫ НИЧЕК КӨРӘШЕРГӘ?

Айгөл ГАБДРАХМАНОВА, Россия авыл хуҗалыгы үзәгенең җитештерү бүлеге җитәкчесе:
– Хәзер колорадо коңгызлары йомырка сала башлый. Бу вакытта биологик ысул белән генә көрәшә алабыз. Ни өчен дигәндә, химик препаратлар йомырка салу фазасында нәтиҗә бирми. Әйтик, подизус дигән файдалы бөҗәк бар. Ул колорадо коңгызының йомыркасы белән туклана. Әлбәттә, аны бөтен кешенең дә сатып алу мөмкинлеге юк. Идел буе федераль округында лаборатор шартларда без генә үрчетәбез. Подизусны Казанга килеп сатып алырга мөмкин, шулай ук район бүлегенә дә җибәрә алабыз. Бер квадрат метрга 2–3 экземпляр кирәк. Берсе – 5 сум. Бөҗәкне ел саен сатып алырга туры киләчәк.

Кортлар барлыкка килгәч, химик һәм биологик препаратлар белән эшкәртеп була. Биологик төренең составында бактерияләр, гөмбәчек булырга мөмкин. Препарат исемнәрен әйтә алмыйм, бу – реклама. Химик төрен сайласагыз, куркынычсызлык классына игътибар итегез. Әйтик, 3–4 нче класслы булса яхшырак. Беренчедән, препаратның Россиядә рөхсәт ителгән пестицид һәм агрохимикатлар исемлегенә керүе мөһим. Анда 3–4 ел тикшерелгән дарулар кертелә. Икенчедән, нормасын саклау. Бүген иң зур проблема булып әлеге корткычларның препаратка тиз ияләнүе тора. Ияләшкәч, тәэсир итми башлый. Еш кына халык: «Моннан ун ел элек файдасы бар иде, хәзер юк», – дип зарлана. Ияләшкәнгә шулай. Шуңа күрә норманы саклагыз. Әгәр 200 миллилитр кушарга дип язылган икән, микъдарын шуннан арттырмагыз. Тизрәк үлсен дип, күбрәк сибү файда бирми. Киресенчә, алдагы елда тагын да күбрәк күләмдә сибәргә кирәк булачак. Нәтиҗәнең яртысы шуңа бәйле.

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар: ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 5315 данә
Гомуми тираж – 14253 данә
Газетага сертификат бирелде Заказ 279

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+